# УКЫТУЧЫМА

*ИФРАТ  ХИСАМОВ  музыкасы*
*ЭНҖЕ  МӨЭМИНОВА  сүзләре*

Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,
Сентябрьнең бере җиткәнен.
Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,
Көтә-көтә арып беткәнем

Иң беренче булып килим, диеп,
Өскә матур яңа күлмәк киеп.
Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй.
Ашыга-ашыга чыгып киткәнем.

Ләкин миннән бик күп алдан килеп,
Хуш киләсең, әйдә, әйдә, диеп,
Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,
Укытучы апам көткәнен.

Шушы көннән башлап безнең өчен
Кызганмады үзенең бөтен көчен.
Безме сөйде, безгә   белем бирде,
Рәхмәт аңа изге эше өчен!